ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ"

# ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫН ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ 7НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘТҮ ӨЧЕН «ТАТАР ТЕЛЕ» ҺӘМ «ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ» ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Казан
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3Тат
Э98

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциясендә

**Төзүче-авторлар:**

Мөхәрләмова Г. Н., Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның хәзерге проблемалары бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

Һадиева Г. В., Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасының өлкән укытучысы

Ханнанова М. Х., Казан шәһәре Идел буе районы «35нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы

Гыйлаҗева Г. Ф., Казан шәһәре Идел буе районы «35нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы

Арсланова Ә. Д., Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35нче гомуми урта белем мәктәбенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Миннегалиева Р. Х., Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35нче гомуми урта белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сафина К. Й., Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35нче гомуми урта белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Фатрахманова Ф. С., Яшел Үзән районы Зур Ключи гомуми урта белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының 7нче сыйныф укучыларына татар телен туган тел буларак өйрәтү өчен «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» предметлары буенча эш программасы / төз.-авт.: Мөхәрләмова Г. Н. һәм башк. – Казан: ТРМҮИ, 2017. – 65 б.

"Татар теле" һәм "Татар әдәбияты" предметларының эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр "Россия Федерациясендә Мәгариф турында"гы Федераль законы, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы, федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һәм гомуми белем бирүнең төп белем бирү үрнәк программаларын исәпкә алып эшләнде.

Методик тәкъдимнәрдә бирелгән материал белем бирү оешмалары җитәкчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, методистлар өчен файдалы булачак.

© ТРМҮИ, 2017

# КЕРЕШ

Һәр уку предметының эчтәлеге укытучы төзегән эш программасында чагылыш таба.

Эш программасы – “педагог тарафыннан конкрет белем бирү оешмасы һәм билгеле бер сыйныф (төркем) өчен үрнәк программа нигезендә төзелгән, эчтәлегендә, темаларны өйрәнү эзлеклегендә, сәгатьләр санында, уку-укытуны оештыру формаларын куллануда һ.б. үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне үз эченә алган уку программасы ул”[1], икенче төрле әйткәндә, ул укытучының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын характерлый торган норматив-идарә итү документ.

Ул түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуы, уку предметының эчтәлеге, программаның бүлек һәм темаларны үз эченә алган календарь-тематик план, белем бирүнең планлаштырылган нәтиҗәләре, әлеге нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү юллары һәм формалары. Гомуми белем бирүнең төрле баскычларында уку-укыту процессы әлеге программадан башка нәтиҗәле итеп оештырыла алмый.

Программаларны эшләү гомуми белем бирү оешмаларының уку-укыту, методик һәм норматив эшчәнлекнең аерылгысыз бер өлеше булып санала. Шул ук вакытта “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы 273нче номерлы Федераль законы уку предметы, курсы, дисциплинасының (модуленең) эш программасы дигән төшенчәне үз эченә алса да, биредә әлеге төр программага куела торган таләпләр билгеләнми, шул сәбәпле укытучы эш программасын төзегән вакытта төрле характердагы сораулар белән очрашырга мөмкин.

Әлеге методик тәкъдимнәрдә әдәбият предметы буенча эш программасының моделен төзү буенча киңәшләр бирелә, эш программасының структурасы, төп өлешләре, аны төзү юнәлешләре билгеләнә.

Аерым уку предметы буенча төзелгән үрнәк программалар эш программасын төзүдә нигез булып тора, шуңа күрә аның билгеле параметрлары эш программасының структурын, өлешләрен төзүдә хезмәт итә.

Эш программасын төзегәндә аның максатларын, бурычларын һәм фукцияләрен истә тоту зарур.

Эш программасының төп максаты – уку-укытуның билгеле бер баскычында төп белем бирү программасын, планда каралган сәгатьләр санына туры килгән аерым уку предметы буенча үрнәк программаның эчтәлеген, дәрестән тыш эшләр планын, өстәмә белем бирү сәгатьләрен гамәлгә ашыру.

Эш программасының түбәндәгеләр тәшкил итә:

- гомуми белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлегенең максатлары, бурычлары һәм укучыларның үзенчәлекләрен исәпкә алып аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, уку материалын өйрәнү тәртибен билгеләү;
- уку еллары һәм белем алу баскычлары эчтәлегенең дәвамчанлыгын тәэмин итү;
- төп гомуми белем бирү оешмасының билгеле бер шартларын, уку ихтыяҗларын һәм укучыларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогик эшчәнлекнең индивидуальлеген чагылдыру.

Эш программасының төп **функцияләре:**

- норматив (эш программасы тулы күләмдә эшләнергә тиеш);
- билгеле бер максатка ирешүне күздә тоту (эш программасы теге яки бу белем бирү өлкәсендә нәтиҗәгә ирешү өчен уку кыйммәтләрен һәм максатларын билгели);

[1] Журин А.А. Рабочая программа по учебному предмету: разработка, экспертиза, утверждение: пособие для учителей и руководителей образовательных учреждений общего образования. – М.: Вентана-Граф, 2013. – Б. 14.

- эчтәлекле (эш программасы укучылар тарафыннан үзләштерергә һәм танып-белергә тиеш булган уку элементларының эчтәлеген, шулай ук аларның авырлык дәрәҗәсен билгеләүне күздә тота);
- процессуаль (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең логик эзлеклелеген, уку-укытуны оештыру формаларын, методларын, чараларын һәм шартларын, шулай ук уку-укыту процессының әлеге предмет буенча дәвамчанлыгын билгели);
- бәя бирүче (эш программасы эчтәлек элементларын үзләштерүнең дәрәҗәсен, контрольгә алынучы объектны, контроль төрләрен һәм укучыларны бәяләү критерийларын ачыклый).

Аерым уку предметы буенча эш программасы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгы буенча эш түбәндәге өлешләрдән торырга тиеш:

1) аерым уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;
2) дәресләрне оештыру формаларын, укучыларның төп эшчәнлек төрләрен күрсәткән аерым уку предметының эчтәлеге;
3) һәр теманы үзләштерүгә бүлеп бирелгән сәгатьләрне күрсәткән календарь-тематик план.

Аерым уку предметы буенча эш программасын килештерү һәм раслауның тәртибе гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

## РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (VIIСЫЙНЫФ) ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

(Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7нче с-ф./ Р.К.Сәгъдиева, Г.Ф.Харисова, Л.К.Сабирҗанова, М.Ә.Нуриева. –Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 215 б. Дәреслеге буенча)

Төзүче-авторлары:

1. Ханнанова Миләүшә Хатип кызы, Казан шәһәре Идел буе районы «35 нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы
2. Гыйлаҗева Гөлнара Фаил кызы, Казан шәһәре Идел буе районы «35 нче лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы

### Аңлатма язуы

7 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы түбәндәге хокукый-норматив документларга нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында” Законы (№273 29.12.2012)
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” Законы (ТРЗ-№ 68 22.07.2013)
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыклары телләре турында” (ФЗ-№126 24.07.1998).
4. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Законы (№ 1560-XII 08.07.1992)
5. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (РФ Мәгариф министрлыгында 1897 нче номерлы боерыгы белән кертелгән 17.12.2010)
6. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда Фән һәм мәгариф үсеше турында дәүләт программасы
7. Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең төп гомуми белем бирүнең төп уку-укыту программасы (ФДББС таләпләренә нигезләнгән).
8. Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына календарь уку графигы.
9. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программа” (V-IX сыйныфлар, төзүчеләр: Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Г.Р.Шакирова. – Казан, 2013.
10. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче с-флар/ [басма өчен Ч.М.Харисава, К.С.Фәтхуллова, З.Н.Хәбибуллин җаваплы]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 239б.
11. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар теленнән программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5-9 нчы сыйныфлар / Р.К.Сәгъдиева, Р.М.Гарәпшина, Г.И.Хәйруллина. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 35 б.
12. Дәреслек: Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. /Р.К.Сәгъдиева, Г.Ф.Харисова, Л.К.Сабирҗанова, М.Ә.Нуриева.- Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 215 б.

***Максат:***

Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә рус мәктәбендә татар теленә өйрәткәндә укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив

(аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлелек) компетенцияләр булдыру.

**Бурычлар:**

- укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;
- татар теле гыйлеме, аның төзелеше, кулланылыш өлкәсе, төп нормалары, сөйләм этикеты, стилистик чаралары белән танышу, сүз байлыгын арттыру;
- тел фактларын анализлый, тел күренешләрен күрә, таба белү сәләтен, тәкъдим ителгән мәгълүматтан мөһимен сайлап ала белү осталыгын үстерү;
- үзләштерелгән белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү;
- дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү;
- үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Предметка гомуми характеристика**

**7нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

**Морфология**:

1. Сүз төркемнәреннән фигыльне, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәрен, хәбәрлек сүзләрне лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясый белү.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

**Сөйләм эшчәнлеге**:

1. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белү.
2. Бирелгән план буенча сочинение язу.
3. Әдәби геройларны сурәтләп бирү.
4. Каралган спектакль буенча хикәя төзү (телдән яки язмача).
5. Программа буенча укылган китапның эчтәлеген сөйләү яки язу, үз фикереңне белдерү.
6. Эш кәгазьләреннән белдерү, бәйрәм белән котлау тексты язу.
7. Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

**Укыту планында предметның тоткан урыны**

Мәктәпнең укыту планы нигезендә 7 нче сыйныфларда татар теле дәресләрен укытуга атнага 3 сәгать бирелә, ел дәвамында 105 дәрес тәшкил итә, эш программасында да уку елы дәвамында 105 дәрес үткәрү планлаштырыла.

**Мәктәп компонентындагы сәгатьләр бүленеше* (һәр мәктәпнең укыту планы буенча)**

| Бүлекләр | Авторлык программасына туры килгән сәгать саны | Мәктәп компонентындагы сәгать саны | Эш программасына туры килгән сәгать саны | Аңлатма |
|---|---|---|---|---|
| Кисәкчәләр | 0 | 1 | 1 | Проект эше (*Йолдызнамә, йолдызлык,*) |
| Барлыгы (сәгать саны) | | | | |

**Предметны үзләштерүнең шәхескә кагылышлы, метапредмет, предмет нәтиҗәләре**

Икенче буын стандартларының нигезен яңа төр мөнәсәбәтләр тәшкил итә: бүген укучының билгеле бер белем дәрәҗәсенә ия булуын дәүләт кенә түгел, ә бәлки укучы, аның эти-әнисе дә дәүләттән билгеле бер күләмдә сыйфатлы белем бирүен таләп итү хокукына ия.

Икенче буын стандартлары шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Нәтиҗәләргә таләпләр – гомуми белем программаларының барлык төрләренең состав өлеше. Алар шәхескә кагылышлы, метапредмет (эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары) һәм предмет буенча (фәнне өйрәнү) нәтиҗәләрне үз эченә ала.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре:**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- татар теленең байлыгын, матурлыгын тоярга өйрәнү, аның чисталыгын саклауга ихтыяҗ булу; туган телне өйрәнүнең әһәмиятен аңлау;
- белем ала белү, тел белеме өлкәсендә белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштерү, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыра белү;
- үзең алган белем күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;

- үзеңне тыңлаучы күзлегеннән анализлый белү, сөйләмне камилләштерергә омтылу;
- үзбәягә сәләтле булу;
- үз текстларыңны язуга кызыксыну булу.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ):**

- танып-белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм шунан чыгып максатлар кую;
- язма һәм телдән тексттагы мәгълүматны аңлый белү (мөстәкыйль рәвештә текстның темасын, күтәрелгән проблеманы ача белү);
- уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мөстәкыйль рәвештә мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- тел берәмлекләрен сөйләм эшчәнлегендә дөрес һәм урынлы файдалана белү, язма сөйләм процессында орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен үтәү;
- билгеле бер темага караган материалны сайлау һәм системалаштыру алымнарын үзләштерү;
- тексттан фактик мәгълүматны аерып ала белү;
- телләр арасындагы уртак проблемаларны, уртак кагыйдәләрне, аермалы якларны күрергә өйрәнү;
- сүзлекләр, сүзлекчәләр, белешмә материаллардан файдалана белү;
- телне әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру;
- үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):***

- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- тыңлый белү, диалогта һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

- үз фикерен тормыштагы мисаллар ярдәмендә дәлилли белү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикереңне язмача һәм телдән тулы һәм төгәл итеп җиткерә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- парларда, төркемдә эшли белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга чыгыш ясый белү.

***Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ):***

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;
- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- укытучы белән бергәләп яки мөстәкыйль рәвештә үз эшеңне, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрдән чыгып эшне оештыру;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль; эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;
- биремнәрне үтәүнең дөреслеген бәяләү.

***Предмет буенча нәтиҗәләр:***

- 1-5 нче сыйныфларда өйрәнгән фонетик, сүз ясалышы һәм лексик закончалыкларны кабатлау;
- 6 нчы сыйныфта өйрәнгән исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык һәм затланышлы фигыльләрне хәтердә яңарту, аларга хас закончалыкларны тирәнәйтү;
- затланышсыз фигыльләр, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәрен өйрәнү,
- укылган текстның эчтәлеген аңлау, үз мөнәсәбәтләрен белдерү, укылган текстка бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү, тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү,- татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итә белү.

**Укучы 7 нче сыйныфны тәмамлаганда сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белем-күнекмәләргә ия булырга тиеш.**

- затланышсыз фигыльләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- аваз ияртемнәре һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- хәбәрлек сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- бәйлек һәм бәйлек сүзләрне белергә, аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- кисәкчәләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- ымлыклар һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;

- модаль сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, бәйләнешле сөйләм төзи белергә;
- проект эшләрен башкара белергә;
- укыган текстның эчтәлеген сөйли алырга, телдән монолог, диалог төзи белергә;
- эш кәгазьләрен язарга белергә.

**Предметның эчтәлеге (105 сәгать)**

**1. 6 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау (7 сәгать)**

Фонетика. Сингармонизм законы. Сүз төркемнәре.

Исем, сан, алмашлык, рәвеш, затланышлы фигыльләр, сыйфат сүз төркемнәрен кабатлау.

**2.Сүз төркемнәре**

***2.1. Фигыль (37 сәгать)***

Фигыль турында төшенчә. Фигыльләрнең ясалышы. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр.

Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, заман формалары, исемләшүе. Сыйфат фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы.

Хәл фигыль, аның мәгънәләре, формалары, сөйләмдә кулланылышы.

Исем фигыль, аның мәгънәсе, формасы, сөйләмдә кулланылышы. Аларның исемгә күчү очраклары.

Татар телендә фигыльләрнең төп формасы буларак сүзлекләрдә бирелүе.

Инфинитив, аның мәгънәсе, формалары, сөйләмдә дөрес кулланылышы һәм дәрес язылышы.

Татар телендә ярдәмче фигыльләрнең кулланылышы. Кайбер мөстәкыйль мәгънәле фигыльләрнең ярдәмче фигыль буларак кулланылу очраклары.

Фигыльләргә морфологик анализ ясау.

Фигыльләрне кабатлау.

***2.2. Аваз ияртемнәре (5 сәгать)***

Аваз ияртемнәре турында төшенчә. Аларның ясалуы, морфологик-синтаксик үзенчәлекләре.

Аваз ияртемнәре нигезендә сүзләр ясалышы.

Аваз ияртемнәренә морфологик анализ ясау.

***2.3. Хәбәрлек сүзләр (3 сәгать)***

Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә. Татар телендә хәбәрлек сүзләрнең тоткан урыны.

Хәбәрлек сүзләрнең формалары һәм җөмләдә кулланылышы.

***2.4. Бәйлекләр (5 сәгать)***

Бәйлек турында төшенчә. Аларның сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләре.

Бәйлекләрне төркемләү. Бәйлек сүзләр, аларның формалары, җөмләдә кулланылышы.

Бәйлекләргә морфологик характеристика бирү.

Бәйлек сүзләр.

***2.5.Теркәгечләр (5 сәгать)***

Теркәгечләр турында гомуми мәгълүмат бирү. Теркәгечләрне куллану үзенчәлекләре, аларның интонациягә бәйле булуы.

Теркәгечләрне төркемләү. Татар һәм рус телләрендә теркәгечләрнең уртак яклары, җөмләдә кулланылышы.

Теркәгечләрне морфологик яктан тикшерү.

***2.6. Кисәкчәләр (5 сәгать)***

Кисәкчәләр. Аларны мәгънәләре буенча төркемләү.

Татар телендә кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

Кисәкчәләргә морфологик анализ ясау.

***2.7. Ымлыклар (3 сәгать)***

Ымлыклар. Аларның ясалу үзенчәлекләре һәм сойләмдә кулланылышы.

***2.8. Модаль сүзләр (2 сәгать)***

Модаль сүзләр турында төшенчә. Аларның җөмләдә кулланылышы.

**3. Морфология буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау (8 сәгать)**

Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәре. Аларның җөмләдә кулланылышы.

Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау.

**4. Бәйләнешле сөйләм үстерү (25 сәгать)**

1. Тыңлаучылар ачык күзалларлык итеп, яратып укыган берәр әдәби әсәрнең төп герое турында (затын үзгәртеп, мәсәлән, “мин” урынына “син” яки “ул” алмашлыкларын кулланып) сөйләү.
2. Мәктәптә уздырылачак берәр чара турында белдерү язу.
3. Бәйрәм белән котлау тексты язу.
4. Грамматик биремле контроль диктантлар язу.
5. Рәсемгә карап, хикәя төзү.
6. Грамматик биремле төрле типтагы диктантлар язу.
7. Программага кертелгән әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне файдаланып, изложениеләр язу.
8. Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәрен кертеп төзелгән җөмләләрне тәрҗемә итү.
9. Экскурсиядә һәм төрле спектакль-концертларда, мәктәптә уздырылган бәйрәм кичәләрендә алган тәэсирләрдән файдаланып, сочинениеләр язу.
10. Картиналар буенча сочинениеләр язу (Иван Хруцкий. “Натюрморт”, Владимир Кочетков. “Кыш килде”, Шамил Якупов. «Урман әкияте», Викентий Лукиянов. “Май”).
11. Текст эчтәлегенә туры китереп план төзү һәм аның буенча сөйләү.
12. Тормыш-көнкүреш темаларына диалоглар һәм монологлар төзү.
13. Бирелгән текстның эчтәлеген орфоэпик нормаларны саклаган хәлдә сөйли белү.
14. Индивидуаль һәм төркемнәрдә проект-фәнни-тикшеренү эше башкару.

## Календарь-тематик планлаштыру[2]

| № | Дәрес темасы | Сәг. саны | Укучы эшчәнлегенә характеристика | Көтелгән нәтиҗәләр | | | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Предмет | Метапредмет | Шәхескә кагылышлы | | План | Факт |
| | | | | **6 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау (7сәгать)** | | | | | |
| 1. | “Исәнме, мәктәп!” темасына әңгәмә. | 1 | Телдән эш | “Исәнме, мәктәп!” темасына диалог төзи белү, телнең коммуникатив функциясен билгели белү | **ТБУУГ:** үзеңнең белем системасында ориентлаша белү, телдән нәтиҗә чыгару, уку проблемасын чишү өчен план төзү.<br>**КУУГ:** үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү, коллектив фикер алуда катнашу. | Төркемдә, парларда эшли белү, башкаларны кабул итү, аңлау | агымдагы | | |
| 2 | 6 нчы сыйныфта өйрәнгән исем сүз төркемен кабатлау. | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш, төркемнәрдә эшләү | Исем сүз төркемен искә төшерү, исемнәрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** үзеңнең белем системасында ориентлаша белү, тексттан фактик мәгълүматны аерып алу.<br>**КУУГ:** үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** максатка ирешү юлларын планлаштыру. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен билгеләү | агымдагы | | |
| 3 | 6 нчы сыйныфта өйрәнгән сан сүз төркемен кабатлау. | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш, төркемнәрдә эшләү | Сан сүз төркемен искә төшерү, саннарны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** үзеңнең белем системасында ориентлаша белү; тексттан фактик мәгълүматны аерып алу.<br>**КУУГ:** бәйләнешле сөйләм, үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү<br>**РУУГ:** эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен билгеләү | агымдагы | | |
| 4 | Алмашлык сүз төркемен кабатлау | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Алмашлык сүз төркемен искә төшерү, алмашлыкларны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** дәреснең проблемасын һәм куелган бурычларны дөрес аңлау; фикерләүнең логик чылбырын төзү.<br>**КУУГ:** коллектив фикер алышуда катнашу.<br>**РУУГ:** эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау | агымдагы | | |
| 5 | Рәвеш сүз төркемен кабатлау | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Рәвеш сүз төркемен искә төшерү, рәвешләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>**КУУГ:** индивидуаль һәм төркемнәрдә эшләү барышында уку хезмәттәшлеге күнекмәләре формалаштыру.<br>**РУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. | Телне өйрәнүгә кызыксыну булу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 6 | Затланышлы | 1 | Затланышлы фигыль | Затланышлы, фигыльләрне | **ТБУУГ:** гомумиләштерүләр, нәтиҗәләр ясый белү; | Үзмаксат кую, үз | агымдагы | | |

[2] Календарь-тематик план мәктәпнең локаль норматив актлары белән билгеләнгән очракта түбәндә күрсәтелгән киңәйтелгән вариантта да (эшчәнлек төрләре, планлаштырылган нәтиҗәләрне һ.б.кертеп) тәкъдим ителергә мөмкин

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фигыль сүз төркемен кабатлау | | төркемчәләренә игътибар итү, нәтиҗә ясау, күнегүләр өстендә язма эш | искә төшерү, аларны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | төп билгеләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>**КУУГ:** мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыру<br>**РУУГ:** үзконтроль. | мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. | | | |
| 7 | Сыйфат сүз төркемен кабатлау | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Сыйфат сүз төркеме турында белемнәрне искә төшерү, сыйфатларны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыру, телдән нәтиҗә чыгару, уку проблемасын чишү өчен план яки модель төзү. Төп билгеләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү; мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү.<br>**РУУГ:** эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү | Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; сөйләмнең сәнгатьлелеген тою. | агымдагы | | |
| 8 | **Сочинение №1** Иван Хруцкий. “Натюрморт” (Мөстәкыйль сүз төркемнәрен кабатлауга) | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Иван Хруцкийның “Натюрморт” картинасы буенча логик бәйләнешне саклап, сочинение яза алу; текстны язганда, татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби нормаларын саклау. | **ТБУУГ:** рәсем буенча эшли белү<br>**КУУГ:** үз фикереңне дөрес итеп белдерә алу.<br>**РУУГ:** үз эшчәнлегеңне оештыра белү. | Үз текстыңны төзүгә кызык-сыну булу; сөйләм камиллегенә омтылу | тематик | | |
| **Фигыль( 37 сәгать)** | | | | | | | | | |
| 9 | Хаталар өстендә эш. Сүз төркемнәре. Фигыль. | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | “Фигыль” төшенчәләренең эчтәлеген белү, фигыльгә хас билгеләрне (зат-сан, заман, барлык- юклык) аера белү фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана алу | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру.<br>**КУУГ:** тыңлый белү, коллектив фикер алышуда катнашу, башкаларның фикерен исәпкә алу.<br>**РУУГ:** кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу. | Үз уңышларыңның/ уңышсызлыклары ның сәбәпләре турында фикер йөртү. | агымдагы | | |
| 10 | Фигыль юнәлешләрен кабатлау. | 1 | Фигыльләрнең лексик-грамматик мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма | “Исем фигыль” төшенчәсенең эчтәлеген белү, аңа хас билгеләрне аера белү, төрле юнәлештәге фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 11 | Фигыльләрнең ясалышы. | 1 | Фигыльләрнең ясалышына игътибар итү, күнегүләр өстендә язма эш | Фигыль ясалыш төрләрен белү, тамыр һәм ясалма фигыльләрне таба һәм аера белү | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматны аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру, уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү.<br>**КУУГ:** коллектив фикер алышуда катнашу.<br>**РУУГ:** иптәшеңнең һәм үзеңнең гамәлләреңне | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану | агымдагы | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | бәяләү | | | | |
| 12 | Фигыль ясагыч кушымчалар | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | "Фигыль ясагыч кушымчалар" төшенчәсенең эчтәлеген белү, ясалма фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә аера, куллана белү | **ТБУУГ:** кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мөстәкыйль рәвештә уку мәсьәләсен формалаштыру | Башка фикерләрне кабул итү, аңлау, үз фикерләреңне җиткерә алу. | агымдагы | | |
| 13 | Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр | 1 | Затланышлы һәм затланышсыз фигыль төркемчәләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш | "Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр" төшенчәсен белү, аларны аера белә, телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** күренешләрне чагыштыру, уку проблемасын чишү өчен план яки модель төзү.<br>**КУУГ:** телдән сөйләү барышында әдәби тел нормаларын үтәү<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 14 | **Диктант №1** "Ямьле Агыйдел буенда" (Тамыр һәм ясалма, затланышлы фигыльләргә карата) | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Сүзләрне дөрес язу; сүзләрне төркемнәр буенча аера белү | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру<br>**КУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ:** хаталарны табу, төзәтү. | Үзбәягә сәләтле булу | тематик | | |
| 15 | Хаталар өстендә эш. Сыйфат фигыль | 1 | Сыйфат фигыльләрне рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш, телдән эш | Сыйфат һәм фигыльнең уртак һәм аермалы якларын күрә белү, "сыйфат фигыль" төшенчәсенең эчтәлеген белү, сыйфат фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;<br>**РУУГ**: хаталарны табу, төзәтү. | Әниләргә карата хөрмәт хисе булдыру, үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 16 | Хәзерге заман сыйфат фигыль | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | Хәзерге заман сыйфат фигыльләрнең төп билгеләрен аера белү, телдән һәм язма сөйләмдә куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматның төп билгеләрен аерып чыгару.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану; сүзләрне урынлы куллана белү | агымдагы | | |
| 17 | Хәзерге заман сыйфат фигыльләрнең исемләшүе, җөмләдә кулланылышы | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | "Исемләшү" төшенчәсенең мәгънәсенә төшенү, исемләшкән хәзерге заман сыйфат фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыру, телдән нәтиҗә чыгару, уку проблемасын чишү өчен план төзү.<br>**КУУГ:** коллектив фикер алышуда катнашу.<br>**РУУГ:** тыңлый белү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Үткән заман сыйфат фигыль | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | “Үткән заман сыйфат фигыль,” төшенчәләренең мәгънәсенә төшенү, үткән заман сыйфат фигыльләрне таный, куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** үрнәк буенча эшли белү; төп билгеләрен аерып чыгару.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 19 | Үткән заман сыйфат фигыльнең исемләшүе, җөмләдә кулланылышы | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Исемләшкән үткән заман сыйфат фигыльләрне аера, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** мөстәкыйль рәвештә кирәкле мәгълүматны таба белү.<br>**КУУГ:** коллектив фикер алышу барышында үз фикереңне дәлилли белү<br>**РУУГ:** коллектив һәм индивидуаль эшне бәяләү | Үз уңышларының (уңышсызлыкларының) сәбәпләре турында фикер йөртү. | агымдагы | | |
| 20 | **Сочинение №2** Владимир Кочетков. “Кыш килде” (Хәзерге һәм үткән заман сыйфат фигыльләрне кабатлау) | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Владимир Кочетковның “Кыш килде” картинасы буенча, логик бәйләнешне саклап, сочинение яза алу; текстны язганда, татар теленең дөрес язу кагыйдәләрен һәм әдәби нормаларын сакый белү. | **ТБУУГ:** картинадагы пейзажны тасвирлый белү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне дөрес итеп белдерә алу.<br>**РУУГ:** уку мәсьәләсен кую. | Үз текстыңны төзүгә кызыксыну булу; сөйләм камиллегенә омтылу; сочинение язу барышында фикерләреңне төгәл һәм ирекле куллану өчен грамматик чараларның һәм сүзлек запасы җитәрлек булу | тематик | | |
| 21 | Хаталар өстендә эш. Киләчәк заман сыйфат фигыль | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | “Киләчәк заман сыйфат фигыль” төшенчәсенең эчтәлеген белү, киләчәк заман сыйфат фигыльләрне таный, куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ**: белешмәлекләрдән, сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны эзли белү.<br>**КУУГ**: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ**: мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Укуга кызыксыну уяту; туган телгә хөрмәт хисе булдыру. | агымдагы | | |
| 22 | Киләчәк заман сыйфат фигыльнең җөмләдә кулланылышы | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Киләчәк заман сыйфат фигыльләрне аера, телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларын формалаштыру, телдән нәтиҗә чыгару, уку проблемасын чишү өчен план төзү.<br>**КУУГ:** коллектив фикер алышуда катнашу.<br>**РУУГ:** укытучы һәм сыйныфташларың белән уку хезмәттәшлеген оештыра белү. | Телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 23 | Тәрҗемә эше. | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | “Сүз тәртибе” төшенчәсенең мәгънәсенә төшенү. Сыйфат фигыльләрне язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** чагыштыру нигезендә нәтиҗәләр ясау.<br>**КУУГ:** дәлилле итеп үз фикерен монологта һәм диалогта башкаларга җиткерә белү.<br>**РУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. | Башкаларныж фикерен кабул итү, аңлау, фикерләреңне җиткерә алу. | агымдагы | | |
| 24 | Сыйфат | 1 | Телдән эш, | Сыйфат фигыль буенча | **ТБУУГ:** төп билгеләрне аерып чыгару. | Үзмаксат кую, үз | агымдагы | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фигыльне кабатлау | | күнегүләр өстендә язма эш | белемнәрне системалаштыру. Аларга морфологик анализ ясый белү. | **КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, эшеңнең уңышлылыгын билгеләү. | мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен билгеләү. | | | |
| 25 | Проект эше | 1 | Проект эше белән танышу. Сорауларга җавап бирү. Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау. | Сыйфат фигыль буенча белемнәрне гомумиләштерү. | **ТБУУГ:** проект эшен башкарганда татар әдәби теленең нормаларын саклау һәм дөрес язу кагыйдәләрен үтәү, тәкъдим ителгән әдәби текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү.<br>**РУУГ:** үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуына төшенү, парларда эшли белү. | Әхлак сыйфатлары булдыру. Проект эшен башкаруга кызыксыну уяту. | тематик | | |
| 26 | Хәл фигыль | 1 | Хәл фигыльләрне рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш, телдән эш | “Хәл фигыль” төшенчәләренең эчтәлеген белү. Хәл фигыльләрне аера, сөйләмдә куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** күренешнең уртак һәм аермалы якларын аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>**КУУГ:** телдән сөйләү барышында татар әдәби теленең нормаларын үтәү. Үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. | агымдагы | | |
| 27 | Хәл фигыльнең төрләре | 1 | Телдән һәм язма эшләр | “Хәл фигыль” төшенчәләренең эчтәлеген белү. Хәл фигыльләрнең төрләрен таный һәм аера, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматның уртак һәм аермалы якларын аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>**КУУГ:** үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. | Сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | агымдагы | | |
| 28 | **Изложение №1** “Эш үткәч үкенүдә файда юк” (Хәл фигыльнең төрләрен кабатлауга) | 1 | Тыңлап аңлау | Текстның эчтәлеген аңлап язу белү | **ТБУУГ:** текстны кыскарту алымнарын белү; текстның төп фикерен формалаштыру; тексттагы һәр абзацка исем бирү; бирелгән тексттан төп мәгълүматны аера белү; план төзи белү; кыска текст төзи белү. Тәкъдим ителгән текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чыгып, логик бәйләнешне саклый алу.<br>**КУУГ:** ишетеп аңлау.<br>**РУУГ:** вакытны контрольдә тоту. | Ирекле фикер йөртү, үз фикереңне дәлилли белергә өйрәнү, үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу. | тематик | | |
| 29 | Хаталар өстендә эш. Хәл фигыльнең кулланылышы. | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Хәл фигыльләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ:** нәтиҗәләр ясау.<br>**КУУГ:** сөйләмне камилләштерүгә омтылу.<br>**РУУГ:** үзеңнең һәм иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү. | Үз уңышларыңнын/ уңышсызлыкларың ның сәбәпләрен ачыклау. | агымдагы | | |
| 30 | Хәл фигыльнең юклык | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә | “Хәл фигыльнең юклык формасы” төшенчәләренең | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматның үзенчәлекләрен истә тотып, кагыйдә формалаштыру. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне | агымдагы | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | формасы. | | язма эш | эчтәлеген белү, юклык формасындагы хәл фигыльләрнең язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. | **КУУГ:** үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** максатка ирешү юлларын планлаштыру. | белү-белмәү чикләрен билгеләү. | | | |
| 31 | Хәл фигыльнең дәрәҗә белән төрләнеше | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | “Хәл фигыль, артыклык дәрәҗәсе, чагыштыру дәрәҗәсе” төшенчәләренең эчтәлеген белү. Дәрәҗә белән төрләнгән хәл фигыльләрне куллана белү. | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматның уртак һәм аермалы якларын аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру; кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Башка фикерләрне кабул итү, аңлау, үз фикерләреңне җиткерә алу. | агымдагы | | |
| 32 | **Диктант№ 2** “Әнием куллары” (Хәл фигыльнең формаларын кабатлауга) | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант текстындагы сүзләрне орфографик, пунктацион нормаларны истә тотып дөрес язу һәм грамматик биремне башкара белү. | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру.<br>**КУУГ:** башкаларны тыңлый белү.<br>**РУУГ:** уку мәсьәләсен кую һәм чишү. | Эшне нәтиҗәле итеп башкаруга омтылыш булу | тематик | | |
| 33 | Хаталар өстендә эш. Хәл фигыльләргә морфологик анализ | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Хәл фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибен белү; сүзгә морфологик анализ ясау (телдән һәм язма). | **ТБУУГ:** фактик мәгълүмат турында белгәннәрне искә төшерү һәм кабатлау, төп билгеләрен аерып чыгару.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Эшне эзлекле эшләү сәләте булдыру | агымдагы | | |
| 34 | Хәл фигыльләрне кабатлау | 1 | Хәл фигыльләрнең лексик-грамматик мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма | Хәл фигыльләрне язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. Аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ:** төп билгеләрен аерып чыгару.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Мөстәкыйль эшләү күнекмәреңне ныгыту | агымдагы | | |
| 35 | Исем фигыль турында төшенчә | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Исем фигыльләрнең лексик-грамматик мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә төшенү, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** уртак һәм аермалы якларны аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштыру, кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** максатка ирешү юлларын планлаштыру. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау | агымдагы | | |
| 36 | Исем фигыльгә морфологик | 1 | Исем фигыльләрнең лексик-грамматик | Исем фигыльләргә морфологик анализ (телдән | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә | Төркем эчендә эшләү | агымдагы | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | анализ | | мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш | һәм язма) ясый белү | белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | күнекмәләрен ныгыту, эшне эзлекле эшләү сәләте булдыру. | | | |
| 37 | Кайбер исем фигыльләрнең исемгә күчүе | 1 | Исемнәрнең һәм исем фигыльләрнең лексик-грамматик мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш | “Исемгә күчү” төшенчәсенең мәгънәсенә төшенү. Сүз төркеме буларак, исемнәрне һәм исем фигыльләрне таный, куллана, аларны аера һәм аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** төп билгеләрне аерып чыгару; фикерләүнең логик чылбырын төзү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Телне өйрәнүгә кызыксыну булу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | агымдагы | | |
| 38 | Исем фигыльләрне кабатлау | 1 | Исем фигыльләрнең лексик-грамматик мәгънәсенә һәм морфологик үзенчәлекләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма | Исем фигыльләрне аера белү, аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ:** төп билгеләрен аерып белү.<br>**КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү.<br>**РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Мөстәкыйль эшләү күнекмәреңне ныгыту | агымдагы | | |
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны 4 тән артса, пунктуацион хаталарның саны 5 тән, грамматик хаталар саны 3 тән артса, «2» ле куела.

**Сочинениенең күләме**

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение – укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия.

Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ.б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинение план нигезендә языла. Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган сочинениенең күләме түбәндәгечә булырга тиеш:

6-7 нче сыйныфларда 1-2 бит.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килүе, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела (1 орфографик яисә 2 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2. Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлар күзәтелсә, 1-2 фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, 2 орфографик, 3 пунктуацион яисә 1-2 сөйләм ялгышы булса, «4»ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, 3 орфографик, 4 пунктуацион яисә 3-4 сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.

4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, 5 орфографик, 8 пунктуацион яисә 4-6 сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

# РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕ (VIIСЫЙНЫФ) ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

(Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә/ Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2014. дәреслеге буенча)

Төзүче-авторлары:

1. Арсланова Ә.Д. – Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35 нче гомуми урта белем мәктәбенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,
2. Миннегалиева Р.Х. – Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35 нче гомуми урта белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,
3. Сафина К.Й. – Казан шәһәре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35 нче гомуми урта белем мәктәбенең беренчеквалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
4. Фатрахманова Ф. С. – Яшел Үзән районы Зур Ключи гомуми урта белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## Аңлатма язуы

7нче сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан эш программасы Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең “Мәгариф турында”гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”).
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан “Об образовании” № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).
3. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы 126-ФЗ нче номерлы Законы (24.07.1998).
4. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (Закон Республики Татарстан от 08.07.1992 № 1560-XII (ред. От 03.03.2012г.) “О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан”).
5. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы, 2004 нче ел, 1нче июль.
6. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы”, 2013 нче ел, 25 нче октябрь, 794 нче карар.
7. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).
8. Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”.
9. Хәсәнова Ф.Ф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5-9 нчы сыйныфлар / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: “Мәгариф -Вакыт” нәшр., 2014. – 51 б.

10. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф- Вакыт” нәшр., 2014. – 143 б.: рәс. Б-н .

Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә. 2 нче кисәк / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф- Вакыт” нәшр., 2014. – 135 б.: рәс. Б-н .

7 нче сыйныф өчен “Татар әдәбияты” курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан программага (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)” 5-9 нчы сыйныфлар, (төзүче-авторлары: Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан, 2014), 7 нче сыйныф өчен Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина тарафыннан төзелгән (Казан: “Мәгариф-Вакыт” – 2015) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар әдәбияты. 7 сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбияты дәреслеге (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан : “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2014 (2 кисәктә)

**Рус телендә белем бирү мәктәбендә татар балаларына татар әдәбияты укытуның максаты** укучыларны сүз сәнгатен аңларга өйрәтүне, татар әдәбияты һәм тәрҗемә әсәрләр аша рус һәм дөнья әдәбияты әсәрләренең байлыгы белән таныштыруны күз алдында тота. Баланы матур әдәбият әсәрләрен форма һәм эчтәлек берлегендә аңларга һәм анализларга өйрәтү, логик фикер йөртүләрен үстерү, рухи дөньяларын баету төп мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әдәби белем бирүнең нигезе – әсәрне уку, анализлау, әсәрне аңлау өчен кирәк булган авторның биографик белешмәләре, тарихи-мәдәни фактлар белән таныштыру.

Татар әдәбияты дәресләренең **төп бурычлары:**

- татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру;
- матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;
- укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- татар халкына, аның әдәбияты һәм мәдәниятенә хөрмәт, дөньяга гуманлы караш, башка халыкларның мәдәниятләре белән кызыксыну тәрбияләү.

***Уку фәненең уку планында тоткан урыны***

Мәктәпнең укыту планы нигезендә 7 нче сыйныфларда татар әдәбияты дәресе укытуга атнага 2 сәгать бирелә, ел дәвамында 70 дәрес тәшкил итә (35 атна), эш программасында да уку елы дәвамында 70 дәрес үткәрү планлаштырыла (программада татар әдәбияты фәне атнага 2 сәгать, ел буена 70 сәгатькә исәпләнгән).

**1. Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Предмет буенча нәтиҗәләр:**

***Танып-белү өлкәсендә***

• Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади укый белү;

• сәнгатьле укый алу;

• кабатлап сөйләүнең төрле төрләрен (тулы итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән) куллана алу;

• шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан белү;
• әсәрләрне анализлый һәм шәрехли алу;
• план төзи алу;
• сочинение элементлары белән изложение яза алу;
• әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение яза белү;
• татар һәм башка халыклар фольклорында, Россия һәм чит ил классиклар иҗатында төп проблемаларны аңлау;
• әдәби әсәрләрнең чор һәм язылышы арасындагы бәйләнеш, аларга салынган вакыт, шәхси кыйммәтләр, аларның яңача яңгырашын аңлау;
• әдәби әсәрләрне анализлый, аларның билгеле бер жанрга каравын белү, теманы аңлый һәм формалаштыра алу, идеясен, әдәби әсәрнең әхлакый ягын табу, геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә герой белән чагыштыра белү;
• композиция, сюжет элементларын, телнең сурәтләү чараларын, аларның әсәр эчтәлеген ачкандагы ролен ачыклау;
• әдәби әсәрне анализлаганда, гади әдәби терминология куллана белү;
• өстәмә белем чыганакларыннан язучыларның тормышы һәм иҗаты турында белү;
• татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында белү;
• әдәби әсәрне, язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау, чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи, сәяси һ.б. мәгълүматлар белү.

***Әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә***

• татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыра алу;
• татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү;
• өйрәнелгән әдәби әсәрләргә аерым очракларда үзгәреш кертә белү;
• автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау.

***Коммуникатив өлкәдә***

• төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп аңлау, аңлаешлы уку, дөрес кабул итү;
• чәчмә әсәрләрне яки өзекләрне татар теленең әдәби чараларын һәм цитаталарын кулланып сөйли белү, укыган яки ишеткән текст буенча сорауларга җавап бирә белү, телдән төрле типтагы монологлар, диалоглар төзи, әңгәмә кора алу;
• бирелгән темага, укылган әсәр темасы, проблемасына изложение яки сочинение, сыйныфта яки өйгә бирелгән иҗади эшләр, гомуммәдәният темаларына реферат яза алу.

***Эстетик өлкәдә***

• Әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әсәрләрдән рухи тәм табу;
• сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау.

**Метапредмет нәтиҗәләре**

- әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны таныргa өйрәтү;
- әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стиле кебек төшенчәләрне җиткерү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша дөнья культурасы, кешелек тарихы төшенчәләрен үзләштерү;
- әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

***Танып белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ)***

- телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;

- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү (төп текст, астөшермә һ.б.), өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;

- укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап);

- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

- үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау (тулы текст, өзек, иллюстрация, схема);

- бер мәгълүматны икенче төрле итеп үзгәртә алу (план төзү, таблица, схема);

- укылган текстның эчтәлеген (яки ишеткәнне), текстка якын итеп, кыскача сайлап сөйли белү;

- сүзлекләр, белешмә материаллардан файдалану;

- анализ ясау, йомгаклау;

- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү.

- төрле мәгълүмат чараларын танып-белү һәм аралашу мәсьәләсен хәл иткәндә (сүзлекләр, энциклопедия, Интернет-ресурслар һ.б.) куллану;

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ)***

- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

- үз фикерен тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү;

- бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;

- күмәк эш вакытында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;

- укылган, тыңланган текстлар буенча сораулар бирә белү;

- үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;

- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;

- үз фикерләрен телдән һәм язма формада җиткерә белү;

- башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;

- иптәшләре каршында төрле темаларга чыгыш ясау.

***Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ)***

– укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;

- максатка ирешү юлларын билгеләү;

- уку проблемасын чишү өчен план төзү;

- шушы план нигезендә эш оештыру, үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күзәтү;

- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

**В. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**

• әхлакый-рухи сыйфатларны камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәттә булу;

• активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәнү, шәхес буларак формалашу;

• үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

• Ватан алдында җаваплылык, милли горурлык, гражданлык хисләре формалашу;

• дәүләт символларына (герб, флаг, гимн) хөрмәт хисенә төшенү;

• әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен белү.

## 2. Курсның эчтәлеге

| № | Төп темалар | Сәгатьләр саны | Теманың кыскача эчтәлеге | Дәрес формасы | Төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес | 1 | Д.Гайнетдинова. Галиҗәнап Китап. Китапның, матур әдәбиятның кеше тормышындагы роле. Атаклы кешеләрнең китап турында әйткән фикерләре | Дәрес-презентация | Текст белән танышу. Китап уку турында әңгәмәдә катнашу. Мөстәкыйль эш башкару |
| **Татар халык авыз иҗаты (11 сәгать)** | | | | | |
| 2 | Риваятьләр | 3 | “Болгар каласының корылуы турында”, “Сихерче кыз” һәм Казанның килеп чыгуы турында риваятьләр.”Казан кайда корылган?”. БСҮ. “Казанның килеп чыгышы турында риваятьләр” Р.Заһидуллинның картинасының фоторепродукциясе | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-экскурсия | Халык авыз иҗаты белән танышу, риваятьләргә билгеләмә бирү, риваятьләрне уку, анализлау, фикер алышу |
| 3 | Легендалар | 2 | “Ярканат ничек дөньяны саклап калган?”, Х.Халиков "Ярканат", “Зөһрә йолдыз” легендалары | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-проект | Текстны уку, сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлек буенча фикер алышу, биремнәр үтәү, проект эшләү |
| 4 | Җырлар | 2 | Казан ханлыгы чорына караган тарихи җырлар. “Сөембикә китеп бара”. "Кайт, Сөембикә" җырын В.Ганиева башкаруында тыңлау. БСҮ. “Тоткын Сөембикә җыруы”. Ф.Халиков. “Казан ханлыгы чорында Кремль” картинасы. Тарихи фактларны чагыштыру. Җыр мотивларын ачыклау | Дәрес-эзләнү, дәрес-презентация, дәрес- проект | Җырның охшаш һәм аермалы якларын табу, тарихи җырларга билгеләмә бирү, презентация карау, җыр тыңлау, фикер алышу |
| 5 | Эпос-дастаннар | 1 | Дастан жанры. “Җик Мәргән” дастаны. Халыкның бәйсезлек өчен көрәше | Дәрес-эзләнү | Текстны уку, анализлау, билгеләмә бирү, фикер алышу, сюжетны билгеләү, текстны өлешләргә бүлеп план төзү |
| 6 | Мәкаль һәм әйтемнәр | 3 | Татар халык мәкаль һәм әйтемнәре. Н.Исәнбәтнең "Мәкальләр һәм әйтемнәр" китабы. Дөнья халыклары мәкальләре. БСҮ. "Күп укыган – күп белгән". Белем турында татар халык мәкальләре | Дәрес-эзләнү, сөйләм үстерү дәресе | Мәкаль-әйтемнәргә билгеләмә бирү, охшаш һәм аермалы якларын табу, мәгънәләрен аңлату, фикер алышу, сочинение язу |
| **Борынгы әдәбият үрнәкләре (2 сәгать)** | | | | | |
| 7 | Сәйф Сараи. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” | 2 | Сәйф Сараи. Биографик белешмә. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” . Өзекләр. Мәхәббәт турында поэма. Шәрыкъ мәхәббәт сюжетлары. Трагедия | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Текстны уку, презентация карау, фикер алышу, сүзлек эше, тексттан сурәтләү чараларын табу, шәрехләү |
| **XVIII йөз әдәбияты (1 сәгать)** | | | | | |
| 8 | “Мәҗмугыл хикәят” | 1 | Хикәят жанры. “Мәҗмугыл хикәят”. Солтан Мәхмүт Газнәви һәм үткен сүзле, зиһенле фәкыйрьләр”. Патша һәм вәзир турында шәрыкъ сюжеты. Мәхәббәт тарихы. Н.Нәкъкаш-Исмәгыйль “Сабак бирә торган әсәрләр” | Дәрес-эзләнү | Белешмәне уку, хикәятләрне уку, фикер алышу, шәрехләү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **XIX йөз әдәбияты (3 сәгать)** | | | | | |
| 9 | Закир Һади. “Мәгъсум” хикәясе | 2 | XIX йөз әдәбияты – татар әдәбияты үсешендә әһәмиятле этап.<br>Закир Һадиның тормыш юлы һәм иҗаты. “Мәгъсум” хикәясе | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Укытучының сөйләвен тыңлау, презентация карау, өзекләрне уку, фикер алышу, биремнәрне үтәү |
| 10 | Ф.Яруллин “Кирәк күңел өчен” шигыре | 1 | Ф.Яруллин “Кирәк күңел өчен” шигыре. Фән-гыйлем турында мәкальләр | Дәрес-эзләнү | Шигырьне сәнгатьле уку, анализлау, әсәр буенча фикер алышу, диспутта катнашу |
| **XX йөз башы әдәбияты (15 сәгать)** | | | | | |
| 11 | Габдулла Тукай иҗаты | 9 | Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты. “Милли моңнар” шигыре. "Әллүки" җырын тыңлау.<br>О.Хәбибуллин. “Тукай портреты” картинасы.<br>М.Хөсәен. “Тукай – шигъри кыябыз”. Х.Казаков. “Бәләкәй Апуш” картинасы. Ф. Казаков турында мәгълүмат.<br>Ф.Нәфиев. “Моңсу бер тарих”. Г.Тукайның Казандагы музее.<br>“Шагыйрь” шигыре.<br>И.Әхмәдиев. “Тукай турында сюита” картинасы.<br>Әхмәт Фәйзи. “Җаек” (“Тукай” романыннан өзекләр) | Дәрес-лекция, дәрес-презентация, дәрес-диспут, дәрес-эзләнү, дәрес-экскурсия, дәрес-проект | Укытучының сөйләвен тыңлау, презентация карау, дәреслектәге материалларны уку, шигырьне сәнгатьле итеп уку, анализлау, дәреслектә бирелгән биремнәрне эшләү, әсәр белән картина өстендә эшләү, проблемалы сорауга җавап эзләү, фикер алышу, романнан өзекләр уку, шәрехләү, гомумиләштереп нәтиҗә ясау. |
| 12 | Дәрдмәнд иҗаты | 2 | Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. “Видаг”, “Бәллү”. туган якны сагыну мотивлары. Дәрдемәнднең шигырьләрне иҗат итүдә шигъри алымнар.<br>Нур Әхмәдиев. “Дәрдмәнд” поэмасы. Шагыйрьнең художестволы уйдырмасы. Биографик материаллар. | Дәрес-эзләнү | Укытучы сөйләвен тыңлау, презентация карау, шигырьләрне сәнгатьле уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, хис-сәбәп нәтиҗәсен ачыклау, төп фикерне аерып чыгару, нәтиҗә ясау. |
| 13 | Г.Ибраһимов иҗаты | 4 | Г. Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Табигать балалары”.<br>Пейзаж. Хезмәтне данлау. Өмәләр. Аларның крестьян тормышындагы әһәмияте. "Өмә" җырын тыңлау.<br>П.Пластовның “Печән өсте”,<br>Р.Заһидуллинның “Печәнгә төшү” картиналары.<br>Г.Сәгыйров. “Җәйге этюд” шигыре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-проект | Укытучының сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү, хикәяне уку, анализлау, идеясен табу, картина белән эшләү, пейзаж хасиятләрен ачыклап төшенчәгә билгеләмә бирү, шигырьне сәнгатьле уку, фикер алышу |
| **1920-1930 нчы еллар әдәбияты (1 сәгать)** | | | | | |
| 14 | Һ.Такташ. “Алсу” поэмасы | 1 | Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗаты. “Алсу” поэмасы. матурлык һәм яшьлек турында поэма. Алсу образы.<br>Поэма төшенчәсе | Дәрес-презентация | Шагыйрь турында мәгълүматны үзләштерү, поэманы уку, сорауларга җавап бирү, образларга бәяләмә бирү, төп фикерне аерып чыгару, әңгәмәдә катнашу, поэманың үзенчәлекләрен билгеләп, төшенчә итеп чыгару |
| **Сугыш чоры әдәбияты (4 сәгать)** | | | | | |
| 15 | Ф. Кәрим иҗаты | 3 | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Бездә яздыр” шигыре. Туган җирне сагыну. | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес- | Укытучы сөйләвен тыңлау, презентация карау, әсәрләрне уку, сорауларга җавап бирү, анализ |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | “Кыңгыраулы яшел гармун”. Юмор. Җиңүгә ышаныч. Туган җиргә мәхәббәт.<br>Ф. Кәрим турында әсәрләр: Х.Әюп. “Кайту”, Р.Мостафин”Өзелергә җитеп, сыкрый күңелем...”,<br>Р.Харис “Өченче ядрә” | диспут | ясау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, тексттан мисаллар табып уку, биремнәрне үтәү, фикер алышу |
| 16 | Г.Кутуй. “Рәссам” | 1 | Г.Кутуйның “Рәссам” хикәясе. Солдатларның картинага мөнәсәбәтләре. Картинада сурәтләнгән ана һәм бала образлары | Дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, эчтәлеге уенча фикер алышу, анализлау, идеясен билгеләү, гомумиләштереп нәтиҗә чыгару |
| **Сугыштан соңгы чор әдәбияты (13 сәгать)** | | | | | |
| 17 | Г.Әпсәләмов. "Миңа унтугыз яшь иде" | 2 | Г.Әпсәләмовның тормыш юлы һәм иҗаты. "Миңа унтугыз яшь иде" хикәясе. Язучының үзенчәлекле стиле. Һәлак булган солдат хикәясе.<br>Сибгат Хәким. “Батырлыкка чакырган кеше”. | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрне укып, ярдәмче сорауларга нигезләнеп, идеясен билгеләү, әңгәмәдә катнашу, проблемалы сорауга җавап эзләү, нәтиҗә чыгару, дәреслектәге мәкаләне уку, гомумиләштерү |
| 18 | С.Хәким иҗаты | 3 | Сибгат Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗаты.<br>“Бакчачылар” поэмасы. Авыл кешеләренең җиңүгә керткән өлешләре. Тыл тормышының авыр көннәре | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Укытучы сөйләвен тыңлау, презентация карау, поэманы уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, анализлау, сурәтләү чараларын табу, нәтиҗә ясау. |
| 19 | Г.Бәширов. “Менә сиңа мә!” | 1 | Гомәр Бәширов. “Менә сиңа мә!” хикәясе. Сугыштан соңгы елларда гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең сурәтләнеше, тол хатыннар проблемасы. Эшчән татар хатын-кызы образы. | Дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, сорауларга җавап бирү, әсәрдәге төп фикерне билгеләү |
| 20 | Ә.Еники иҗаты | 4 | Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты. "Кем җырлады?" хикәясе. Трагизм.<br>БСҮ. "Кем җырлады?" хикәясе буенча сочинение.<br>ДТУ. "Мәк чәчәге" нәсере. Нәсер жанрына билгеләмә | Дәрес-презентация, Дәрес-эзләнү, бәйләнешле сөйләм үстерү, дәрестән тыш уку дәресе | Укытучының язучы турында сөйләвен тыңлау, презентация карау, дәреслектәге материаллар белән танышу, хикәяне уку, анализлау, татар җыры туры фикер алышу, нәсер жанрына билгеләмә бирү, әсәрдән алган хис-кичерешләргә нигезләнеп иҗади эш башкару, дәрестән тыш әдәби әсәрне уку, эчтәлеген сөйли алу, фикер алышу, гомумиләштереп нәтиҗә ясау |
| 21 | И.Гази. "Йолдызлы малай" | 1 | И.Газиның тормыш юлы һәм иҗаты. "Йолдызлы малай" хикәясе. Фашистларның ерткычлыгы. Малайның үлем алдыннан халәтенең бирелеше | Дәрес-эзләнү | Язучы иҗатына күзәтү ясау, хикәяне уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү, төп геройга бәяләмә бирү, нәтиҗә ясау |
| 22 | Р. Низами. "Блокада хатирәсе" | 1 | Рашат Низаминың "Блокада хатирәсе" хикәясе | Дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, сорауларга җавап бирү, тексттан мисаллар табып уку, хикәядәге төп фикерне билгеләү, тема буенча әңгәмәдә катнашу |
| 23 | ДТУ. Повесть. | 1 | Сайлап алынган язучының повестен укып, сюжетын сөйләү. Повесть жанры | Дәрес-эзләнү | Дәрестән тыш уку өчен бирелгән повесть жанрындагы әсәрне уку, сюжеты буенча фикер алышу, повесть жанры хасиятләрен ачыклап, билгеләмә бирү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **1960-1980 нче еллар әдәбияты (7 сәгать)** | | | | | |
| 24 | М. Мәһдиев. “Без кырык беренче ел балалары” | 5 | М. Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗаты. “Без кырык беренче ел балалары” повесте. Сугыш һәм сугыштан соңгы чор еллары авырлыгы. Язучының үзенчәлекле стиле. Повестьтагы юмор. Гөберчәктәге М.Мәһдиев музее | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү, дәрес-экскурсия, дәрес-проект | Язучы турында укытучы сөйләвен тыңлау, презентация белән танышу, повестьтан өзекләр уку, фикер алышу, геройларга характеристика бирү, әңгәмәдә катнашу, дәреслектәге материаллар белән танышу, виртуаль экскурсиядә катнашу, гомумиләштереп нәтиҗә ясау, проект эше башкару |
| 25 | Т.Миңнуллин. “Монда тудык, монда үстек” | 2 | Т. Миңнуллинның “Монда тудык, монда үстек” драмасы. Нефтьчеләр турында драма. Табигатьне саклау проблемасы. Драма төшенчәсе | Дәрес-презентация, дәрес-эзләнү | Презентация карау, әсәрне уку, сорауларга җавап бирү, рольләргә бүлеп уку, драма төшенчәсен чыгару, нәтиҗә ясау |
| **Хәзерге әдәбият (5 сәгать)** | | | | | |
| 26 | М. Галиев. “Нигез” | 5 | М. Галиевның “Нигез” повесте. Ялгыз Тал образы. Халыкның этнографик традицияләре. Мифология белән бәйләнеш | Дәрес-эзләнү, дәрес-диспут, дәрес-проект | Повестьны уку, эчтәлеген ачыклау, анализлау, фикер алышу, төп идеяне билгеләү, әсәр турында әйтелгән фикерләр белән танышу, проект эшен башкару |
| **Тәрҗемә әсәрләр (3 сәгать)** | | | | | |
| 27 | А. Пушкин. “Кышкы кич”, “Мин яраттым, Сезне!”. Л. Шагыйрьҗан. "Минем дә үз Пушкиным бар" | 2 | А. Пушкинның “Кышкы кич”, “Мин яраттым, Сезне!” шигырьләре.<br>Л.Шагыйрьҗан. "Минем дә үз Пушкиным бар" | Дәрес- презентация, дәрес-эзләнү | Шагыйрьнең биографиясен искә төшерү, шигырьләрне уку, эчтәлекләре буенча фикер алышу, хис-сәбәп бәйләнешләрен ачыклау, сурәтләү чаралары өстендә эшләү |
| 28 | М. Лермонтов “Болытлар” | 1 | М.Лермонтовның “Болытлар” шигыре | Дәрес-эзләнү | Шигырьне уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, хис-сәбәп бәйләнешләрен ачыклау, сурәтләү чаралары өстендә эшләү |
| **Фантастик әсәрләр (2 сәгать)** | | | | | |
| 29 | А.Тимергалин.“Сәер планетада” | 1 | А.Тимергалинның “Сәер планетада” хикәясе. Фантастика һәм чынбарлык | Дәрес-эзләнү | Фантастик эчтәлекле хикәяне аңлап уку, әсәр буенча фикер алышу, биремнәр үтәү, телдән сурәтләп хикәя төзү |
| 30 | Р. Фәизов. “Бер күбәләк” | 1 | Р. Фәизовның “Бер күбәләк” хикәясе.<br>Табигатьне саклау проблемасы.<br>Фантастика жанрына билгеләмә | Дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү, фантастика жанрына билгеләмә бирү, гомумиләштереп нәтиҗә ясау. |
| **Балалар әдәбияты (1 сәгать)** | | | | | |
| 31 | Г.Гыйльманов. “Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса” | 1 | Г. Гыйльмановның “Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса”сы. Табигатьне саклау | Дәрес-эзләнү | Хикәяне уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, геройларга характеристика бирү, биремнәрне үтәү |
| 32 | Кабатлау, йомгаклау | 1 | Ел буе үткәннәрне йомгаклау<br>Р. Фәйзуллинның “Бердәнбер”, Г. Афзалның “Акыл, намус, белем” шигырьләре | Йомгаклау дәресе | Шигырьләрне уку, анализлау, төп фикерне билгеләү, ел буена үткәннәргә гомумиләштереп йомгак ясау |
| | Барлыгы: | | | 70 | |

**Минимум**

*Татар язучылары әсәрләре:*

1. Г.Тукай. «Милли моңнар»
2. Г.Ибраһимов«Табигать балалары» (өзек).
3. С.Хәким. «Бакчачылар»
4. Һ.Такташ. «Алсу».
5. Ф.Кәрим. «Бездә - яздыр»
6. Г.Кутуй. «Рәссам»
7. Ә.Еники. «Кем җырлады?»
8. Г.Бәширов. «Менә сиңа мә!»
9. И.Гази. «Йолдызлы малай»
10. М.Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары» (өзек)
11. М.Галиев. «Нигез» (өзек);
12. Т.Миңнуллин. «Монда тудык, монда үстек»

*Язучы биографияләре белән танышу:*

1. Г.Тукай,
2. С.Хәким,
3. Г.Әпсәләмов,
4. Ә.Еники (бер әсәр буларак карала).

*Тәрҗәмәләр:*

1. А.Пушкин. «Кышкы кич»

Әдәби әсәрләрне өйрәнү – 52
Сөйләм үстерү – 10
Дәрестән тыш уку – 4
Сочинение – 4

**Яттан өйрәнү өчен**

1. Г.Тукай. «Милли моңнар»
2. Дәрдемәнд. «Видаг» яки «Бәллү»
3. Һ.Такташ. «Алсу» (өзек)
4. Г.Ибраһимов. «Табигать балалары»
5. Ф.Кәрим. «Кыңгыраулы яшел гармун»

# 3. Календарь-тематик план[1]

| № | Дәреснең темасы | Эшчәнлек төрләре | Планлаштырылган нәтиҗәләр | | | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәхескә бәйле | метапредмет | предмет | | | |
| **Кереш (1 сәгать)** | | | | | | | | |
| 1 | Б.С.Ү. Галиҗәнәп Китап | Текстны уку, фикер алышу, төрле халык язучыларының китап турындагы фикерләрен укып, фикер алышу | Китапка һәм китап укуга мәхәббәт хисе булу. Кеше тормышында китапның ролен аңлау | Төрле халыкларның фольклор үрнәкләре турында мәгълүмат алу, аларны чагыштырып анализлау. Фикер йөртүнең логик чылбырын төзү, гомумиләштерүләр ясау, уку материалыннан файдалану; әңгәмәдә катнашу, дәлилләү; башкаларның җавапларын бәяләү, үзбәя | "Галиҗәнәп Китап" мәкаләсе белән танышу | | | |
| **Халык авыз иҗаты (11 сәгать)** | | | | | | | | |
| 2 | Татар халык авыз иҗаты. Риваять.<br>“Болгар каласының корылу турында” | Халык авыз иҗаты белән танышу, фольклор төрләрен искә төшерү, мисаллар китерү.<br>риваятькә билгеләмә бирү,әсәрдә бирелгән риватьләрне уку, фикер алышу | Татар халкының теленә, диненә, мәдәни мирасына хөрмәт белән карау | Төшенчә итеп чыгару, белемнәрне синтезлау, укылган тексстан кирәке информацияне аерып чыгару; фикерләрне төгәл һәм ачык итеп әйтә белү, хезмәттәшлек итү; уку мәсьәләсен тәгъбир итү, башкаларның җавапларын контрольдә тотып бәяләү | Халык авыз иҗатын гомуми күзаллый алу. Риваять һәм легендалар турында мәгълүмат алу; Риваятьнең халык авыз иҗатының башка төрләреннән нәрсә белән аерылуын белү | | | |
| 3 | «Сихерче кыз» риваяте | Сорауларга җавап эзләү, «Сихерче кыз» риваяте белән танышу, фикер алышу, анализлау | Халык авыз иҗаты әсәре – риваятькә карата кызыксыну хисе булу | Объектларны чагыштырып, мөстәкыйль нәтиҗә ясый белү, өйрәнелгән текстка бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерү, үзбәя | «Сихерче кыз» риваятенең эчтәлеген белү, анализлый алу | | | |
| 4 | БСҮ. Казанның килеп чыгышы<br>турында риваятьләр | Казанның килеп чыгышы турында риваятьләр белән танышу, фикер алышу, анализлау | Милли горурлык, гражданлык хисләре формалашкагн булу | Белемнәрне структуралаштыру, синтезлау, билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау; монолог төзү, әңгәмәдә катнашу, фикерләрне дәлилле итеп җиткерү; фаразлау, үзбәя | Риваять һәм аның үзенчәлекләре турында белемле булу. Тарихи һәм топонимик риваятьләрне чагыштыра алу | | | |

[1] Календарь-тематик план мәктәпнең локаль норматив актлары белән билгеләнгән очракта түбәндә күрсәтелгән киңәйтелгән вариантта да (эшчәнлек төрләре, планлаштырылган нәтиҗәләрне һ.б.кертеп) тәкъдим ителергә мөмкин

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Легендалар. «Ярканат ничек итеп дөньяны саклап калган?» | Легендалар белән танышу, өзекне сәнгатьле итеп уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеге буенча фикер алышу | Борынгы әдәбият хәзинәләренә хөрмәт, алар белән кызыксыну хисе булу | Билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, чагыштыру, өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү; сорауларга җавап бирү, фикерләрне тәгъбир итә алу; уку мәсьәләсен кую, планлаштыру, бәяләү | Легенда жанрын, риваять белән чагыштыру. Охшаш һәм аермалы якларын билгели алу | | | |
| 6 | «Зөһрә йолдыз» легендасы | Монологик төзү, төркемнәрдә эшләү, сорауларга һәм биремнәргә җаваплар табу | Халык авыз иҗатына мәхәббәт хисенә төшенү | Билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, тексттан төп фикерне аерып чыгару; фикерләрне дәлилле итеп җиткерү; билгеле бер күрсәтмә нигезендә эшли белү, бәяләү | Легенданы аңлап һәм иҗади укый алу, легендага хас билгеләрне белү | | | |
| 7 | Казан ханлыгы чорына караган тарихи җырлар | Җыр төрләре белән танышу, аларның охшаш һәм аермалы якларын табу “Тарихи җыр” терминын китаптан уку. Тарихи җырлар белән танышу, сорауларга җавап бирү, авыр аңлаешсыз сүзләрне ачыклау, сүзлек белән эш. Презентация карау, сорауларга җавап эзләү, фикер алышу | Гыйлемнең кирәклеген, дуслыкның кадерен аңлау. | Җырларны тормыш белән бәйли белү. Текстларда әйтергә телгән төп фикерне таба, нәтиҗәләр ясый алу, төшенчә итеп чыгару; башкаларның фикерләрен тыңлый белү, әңгәмәдә катнашу; башкаларның җавапларын бәяләү | Җырларны белү, аларда күтәрелгән проблемаларның тарихи яктан мөһимлеген аңлау | | | |
| 8 | СТҮ.”Тоткын Сөембикә җыруы” | Сөембикә турында белемнәрне искә төшерү, фикер алышу. Җырны уку, тыңлау, өлешләргә бүлү, анализлау. Интернеттан Сөембикә турында өстәмә мәгълүмат табу, фикер алышу | Хатын-кызга хас матур сыйфатлар төшенчәсен аңлау, милли җанлы, тәвәккәл булу хисе теләге уяну | Танып-белү мәсьәләсен аңлау, тыңлап аңлау, билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектны анализлау, мәгълүмати эзләнү ысулларын куллану; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне ачык һәм төгәл итеп җиткерү; үзбәя | ”Тоткын Сөембикә җыруы”ның эчтәлеген белү. Сөембикәең халкына, дәүләтенә карашын билгеләү | | | |
| 9 | Эпос-дастаннар. «Җик Мәргән» | Эпос-дастан жанрының билгеләмәсен бирү, “Батыр” сүзенең мәгънәсен аңлату, фикер алышу. Дастанны уку, геройга хас сыйфатларны табу (гипербола). Әсәрнең сюжетын билгеләү, өлешләргә бүлеп, план төзү | Батырлык төшенчәсен аңлау | Рус әдәбиятыннан, татар халык авыз иҗаты әсәрләреннән пәһлеваннар турында мисаллар чагыштыру. Конкрет шартлардан чыгып мәсьәләләрне хәл итүнең нәтиҗәле юлларын сайлап алу, белемнәрне синтезлау, структуралаштыру; фикерләрне ачык һәм дөрес итеп җиткерү; план буенча эшләү | «Җик Мәргән» дастанының эчтәлеген белү, анализлый алу. Эпос-дастан төшенчәсен аңлау | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | эшчәнлекнең нәтиҗәләренә контроль ясау һәм бәяләү | | | | |
| 10 | Мәкальләр һәм әйтемнәр | Мәкаль һәм әйтемнәрнең билгеләмәсен бирү, охшаш, аермалы якларын табу. Н.Исәнбәтнең “Мәкальләр һәм әйтемнәр” китабы белән танышу, ошаган мәкальләрне язып алу, мәгънәләрен аңлату | Мәкальләрнең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау | Сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү, фикер йөртүнең логик чылбырын төзү, гомумиләштерүләр ясау; дәлилләү, хезмәттәшлек итү; билгеле бер күрсәтмәләр нигезендә эшләү, үзбәя | Мәкаль белән тормыш тәҗрибәсе арасындагы бәйләнешне тоярга өйрәнү. Мәкальләрне сөйләмдә кулланырга өйрәнү | | | |
| 11 | БСҮ. Сочинение язу. «Күп укыган – күп белгән» | Тема буенча фикер алышу, сүзлек өстендә эшләү, сорауларга җавап бирү, терәк сүзләр кулланып, сочинение язу. | Белемнең алтын-көмеш, затлы киемнәрдән өстен булуына төшенү | Татар һәм рус әдәбиятларыннан уку турында мәкальләрне чагыштыру. Материалны аерып алу, үз фикерләрен бәян итә алу, план төзү, үзбәя | Китапларның бүгенге көндә дә актуальлеген аңлау, сочинение яза алу | | | |
| 12 | Дөнья халыклары мәкальләре | Интернеттан төрле халыкларның мәкальләрен язып алу, мәгънәләрен аңлату, аларда тема уртаклыгын табу, чагыштыру, фикер алышу | Мәкальләрнең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау | Текстларда фикер уртаклыгын эзләү, үзара чагыштыру, классификацияләү гамәлләрен тормышка ашыру, нәтиҗә чыгару; үз позициясен тәгъбир итү; контроль-коррекция гамәлләрен башкару | Мәкальләргә салынган фикерләрнең мәгънәләренә төшенү | | | |
| **Борынгы әдәбият (2 сәгать)** | | | | | | | | |
| 13 | Сәиф Сараиның “Сөһәйл вә Гөлдерсен ” әсәре | Борынгы әдәбият турында белгәннәрне искә төшерү, “Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре” мәкаләсе буенча фикер алышу, сорауларга җаваплар, презентация карау сүзлек эше, өзекләрне уку, тексттан сурәтләү чараларын табу, дәфтәрләрдә эшләү | Борынгы әдәбият үрнәкләренә кызыксыну уяну. Хөрмәт хисен аңлау | Танып-белү мәсьәләсен аңлау, аңлап уку, уку мәсьәләсен чишү өчен тамга-символик чараларны куллану, билгеләрне аерып чыгару максаты беән объектларны анализлау, тексттан кирәкле информацияне таба белү,; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне ачык һәм төгәл итеп җиткерү; үзбәя | Борынгы әдәбият турында гомуми күзаллаулы булу. Сәиф Сараиның иҗаты һәм тормышы белән таныш булу. “Сөһәйл вә Гөлдерсен ” әсәренең эчтәлеген белү. Әсәр иҗат ителгән чор һәм тарихи шәхесләр турында кыскача мәгълүматлы булу | | | |
| 14 | Сәиф Сараиның “Сөһәйл вә Гөлдерсен” әсәре | Коперник һәм Д.Бруно турында Интернетта бирелгән мәгълүматлар белән танышу, фикер алышу, әсәрдәге өзекләрне сәнгатьле һәм аңлап уку, шәрехләү; сүзлек эше | Борынгы әдәбият үрнәкләренә хөрмәт белән карау, милли горурлык хисләренә төшенү | Әдәбиятның фән белән бәйләнешен ачыклау. Уку мәсьәләсен чишү өчен анализ, синтез, чагыштыру гамәлләрен тормышка ашыру, мәгълүмати эзләнү ысулларын куллану, гомумитләштерүләр ясау; әңгәмәдә катнашу, коммуникатив | Әсәр иҗат ителгән чор һәм тарихи шәхесләр турында мәгълүматлы булу. “Сөһәйл вә Гөлдерсен ” әсәренең эчтәлеген белү, | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәсьәлә белән бәйле рәвештә сөйләм чараларын куллану; фаразлау, планлаштыру, бәяләү | шәрехли алу | | | |
| **XVIII йөз әдәбияты (1 сәгать)** | | | | | | | | |
| 15 | Хикәят жанры. “Мәҗмугыл- хикәят” әсәре | Хикәят жанры үзенчәлекләрен билгеләп төшенчә итеп чыгару, Нәҗип Нәкъкаш мәкаләсе белән танышу, мәкалә буенча фикер алышу, дәреслектә бирелгән хикәятләрне уку, рольләргә бүлеп уку, гыйбрәтле вакыйгаларга нигезләнгән үгет-нәсыйхәтләр турында төркемнәрдә фикер алышу | Борынгы хәзинәбезгә карата кызыксыну һәм хөрмәт хисләре уяну | Синтезлау – өлешләрдән бөтен төзү, төшенчә итеп чыгару, дәреслек материалында кирәкле информацияне табу, аңлап уку; фикер алышуда катнашу, төркемнәрдә эшләп хезмәттәшлек итү; үз эшчәнлекләрен планлаштыру һәм оештыру, бәяләү | XYIII йөз турында тарихы турында белү. “Мәҗмугыл- хикәят” җыентыгында бирелгән хикәятләрнең эчтәлеген белү. Хикәят жанрын аңлау | | | |
| **XIX йөз әдәбияты (3 сәгать)** | | | | | | | | |
| 16 | Закир Һадинең “Мәгъсум” хикәясе | Автор белән танышу, презентация карау, сүзлек эше, өзекләрне уку, Хәят абыстайның киңәшләре буенча фикер алышу, биремнәрне үтәү | Әниләргә ихтирамлы булу, биргән киңәшләрне истә тоту | Өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү, куелган максаттан чыгып, тексттан фрагментлар аерып чыгару, нәтиҗә ясау; фикер алышуда катнашу, фикерләрне ачык һәм төгәл җиткерү; билгеле бер күрсәтмәләр нигезендә эшләү, контроль, бәяләү | XIX йөздә мәгариф системасы һәм мәдрәсәләр турында мәгълүматлы булу. Закир Һадиның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныш булу, “Мәгъсум” хикәясеннең эчтәлеген белү, анализлый алу | | | |
| 17 | Закир Һадинең “Мәгъсум” хикәясе | Дәреслек, дәфтәр белән эш, яңа сүзләрне активлаштыру – җөмләләр төзү, сайлап уку, Вәлид, Гариф образларына характеристика бирү, биремнәрне башкару, XIX йөздәге мәдрәсәләр һәм бүгенге мәктәп турында фикер алышу | Белем алуга ихтыяҗ һәм омтылыш хисе булу | Дәреслек материалында кирәкле информацияне табу, аңлап уку, гомумиләштерүләр ясау, билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау; тыңлау һәм башкаларның сорауларына җавап бирү, тел нормаларына туры китереп, монолог төзү; бәяләү | “Мәгъсум” хикәясеннең эчтәлеген белү, анализлый алу. Иске типтагы мәдрәсәләрдә белем һәм тәрбия бирү тәртипләре турында мәгълүматлы булу | | | |
| 18 | Белем алу – энә белән кое казу | Презентация ярдәмендә Ф.Яруллинның тормышы белән кыскача танышу, алдагы сыйныфларда | Белем алуның “энә белән кое казу” икәнлеген, киләчәк өчен бик | Тыңлап аңлау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр чыгара белү урнаштыра белү; хезмәттәшлек итү, | Фән-гыйлем турында мәкальләр һәм Ф.Яруллинның “Кирәк күңел өчен” | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өйрәнгән әсәрләрен искә төшерү, “Кирәк күңел өчен” шигырен актер башкаруында тыңлау, текстны уку, төркемнәрдә фикер алышу, мәкальләрнең мәгънәләрен аңлату, “Белем – байлык” темасына диспут оештыру | тә мөһим булуын аңлау | әңгәмәдәшенең тәртибенә җитәкчелек итү, үз позициясен тәгъбир итү, конфликтларны чишү; җавап алгоритмын планлаштыру, бәяләү | шигыре белән таныш булу. Белемнең кешелек дөньясы өчен әһәмияте турында белү | | | |
| **XX йөз әдәбияты (15 сәгать)** | | | | | | | | |
| 19 | Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, биографик белешмәне уку, әсәрләреннән күргәзмә карау, алдагы сыйныфларда өйрәнгән әсәрләрне искә төшерү, төркемнәрдә фикер алышу, сорауларга җавап бирү, шагыйрь булган урыннарны барлау, хронологик таблица төзү | Язучы иҗатына кызыксыну уяну, шигырьләрен укырга теләк туу | Белемнәрне структуралаштыру, уку мәсьәләсен чишү өчен анализ, синтез, чагыштыру, классификацияләү гамәлләрен тормышка ашыру, нәтиҗәләр чыгару; үзенең карашын әйтү һәм дәлилләү; үз эшчәнлекләрен планлаштыру һәм оештыру, бәяләү | Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗатын белү. Әдип яшәгән чор турында гомуми күзаллаулы булу | | | |
| 20 | Г.Тукайның “Милли моңнар” шигыре | Шигырьне актер башкаруында тыңлау, анализлау, төркемнәрдә фикер алышу, язылу тарихы белән танышу, сүзлек белән эш, сораулар һәм биремнәрне үтәү, “Әллүки” көен тыңлау, О.Хәбибуллинның “Тукай портреты” исемле картинасы өстендә эшләү | Милли үзаң төшенчәсен аңлау, милләткә карата ихтирам хисе уяну | Тыңлап аңлау, рәсем сәнгате ярдәмендә тәкъдим ителгән информацияне аңлау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү, нәтиҗә чыгару; сорауларга җавап бирү, коммуникатив мәсьәлә белән бәйле рәвештә сөйләм чараларын куллану; кирәкле гамәлләрне укытучы һәм сыйныфташлары белән берлектә планлаштыру, бәяләү | Г.Тукайның “Милли моңнар” шигыренең эчтәлеген белү, анализлый алу, “Милли хис”, “милли көй”, “милли сыйфатлар” төшенчәләрен аңлау | | | |
| 21 | Мәхмүт Хөсәеннең “Тукай- шигъри кыябыз” шигыре | Тукай белән бәйле урыннар, аңа багышланган әсәрләр турында әңгәмә уздыру, шигырь циклы турында аңлату, шигырьне актер башкаруында тыңлау, дәфтәрләрдә Тукайны характерлый торган чагыштыруларны, эпитетларны язу, сәнгатьле уку | Тукай иҗатын һәм аңа багышланган әсәрләрне өйрәнү аша шагыйрьнең татар тормышындагы ролен аңлау | Тыңлап аңлау, фикерләрне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән формада төзү, текстан кирәкле информацияне аерып алу; әңгәмәдә катнашу, сорауларга дөрес җавап бирү; уку гамәлләрен башкару, үзбәя | Мәхмүт Хөсәеннең “Тукай- шигъри кыябыз” шигыренең эчтәлеген белү, идеясен билгели алу. Цикл турында төшенчәне аңлау. Тукай образының сәнгатьтә бирелешен аңлау | | | |
| 22 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Х.Казаковның | Г.Тукайның “Исемдә калганнар” әсәре белән | Шәфкатьлелек, кызгана белү | Әдәбият һәм рәсем сәнгатенең бәйләнеше турында сөйләшү. Рәсем | Х.Казаковның “Бәләкәй Апуш” | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
